**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 31 гыйнвар № 43

г. Казань

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном учреждениесе исемен үзгәртү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном учреждениесе исемен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга таба – учреждение) дип үзгәртү турындагы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе уставына тиешле үзгәрешләрне кертергә;

ел саен Уставында күздә тотылган төп эшчәнлек нигезендә учреждение өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен расларга.

3. Учреждениенең дәүләт йөкләмәсен үтәвен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бер ай эчендә «Костер» республика балалар савыктыру-белем бирү үзәге» дәүләт бюджет өстәмә белем бирү учреждениесенең оператив идарәсеннән түбәндәге адреслар буенча урнашкан, учреждение эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен алырга һәм учреждениегә оператив идарә хокукында беркетергә:

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт, гомуми мәйданы – 831,3 кв.метр (1 нче корпус бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт гомуми мәйданы – 698,1 кв.метр (16 нчы корпус бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт гомуми мәйданы – 688,2 кв.метр (2 нче А корпусы бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт гомуми мәйданы – 702,1 кв.метр (26 нчы корпус бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт гомуми мәйданы – 2 726,8 кв.метр (хуҗалык-көнкүреш корпусы бинасы (3 нче корпус));

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт гомуми мәйданы – 2 154,5 кв.метр (йокы блогы бинасы (4 нче корпус));

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт гомуми мәйданы – 1 827,9 кв.метр (медицина корпусы бинасы);

Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Прибольничная урамы, 15 нче йорт гомуми мәйданы – 49,9 кв.метр (трансформатор ярдәмче станциясе бинасы).

5. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына законнарда билгеләнгән тәртиптә учреждениегә даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга Шәһәр яны урманчылыгындагы Биектау участок урманчылыгының 95 нче кварталында урнашкан 9,0 гектар гомуми мәйданлы урман кишәрлеген бирүне тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Республика олимпиада үзәге» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе уставына кертелгән үзгәрешләрне теркәгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына аларны әлеге карарның 1 нче пунктына туры китерү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

7. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\43.doc